ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ
ГОРОД НАБЕРЕЖНЫЕ ЧЕЛНЫ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЯР ЧАЛЛЫ ШӘҺӘРЕ
МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

19 февраль 2026ел № 1623

Яр Чаллы шәһәренең «Шәһәр хуҗалыгы дирекциясе» муниципаль автономияле учреждениесе тарафыннан күрсәтелә торган хезмәтләргә чик тарифларны раслау турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 17 статьясындагы 1 өлешнең 4 пункты, шәһәр Уставының 41 статьясы, Шәһәр Советының 2007 елның 21 февралендәге 19/8 номерлы Карары белән расланган Муниципаль хокукый актлар системасы турында нигезләмәнең 5.21, 5.22 пунктлары, Шәһәр Советының 2008 елның 19 ноябрендәге 35/7 номерлы Карары белән расланган Муниципаль предприятиеләрнең һәм учреждениеләрнең хезмәтләренә тарифлар билгеләү турында карарлар кабул итү тәртибе хакында нигезләмәнең 5 пункты, Башкарма комитетның 2013 елның 1 ноябрендәге 6561 номерлы Карары белән расланган Муниципаль унитар предприятиеләрнең һәм муниципаль учреждениеләрнең хезмәтләренә тарифларны исәпләү тәртибе турында нигезләмә нигезендә

К А Р А Р  Б И Р Ә М:

1. Яр Чаллы шәһәренең «Шәһәр хуҗалыгы дирекциясе» муниципаль автономияле учреждениесе тарафыннан күрсәтелә торган хезмәтләргә чик тарифларны кушымтада каралганча расларга.

2. Башкарма комитетның «Яр Чаллы шәһәренең «Шәһәр хуҗалыгы дирекциясе» муниципаль автономияле учреждениесе тарафыннан күрсәтелә торган хезмәтләргә чик тарифларны раслау турында» 2025 елның 7 маендагы 3325 номерлы Карары үз көчен югалткан дип танырга.

3. Башкарма комитетның эш кәгазьләрен алып бару идарәсенә әлеге карарны «Челнинские известия», «Шәһри Чаллы» вакытлы матбугат басмаларында, Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында (https://pravo.tatarstan.ru) рәсми бастырып чыгаруны һәм аны

«Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә https://nabchelny.ru адресы буенча Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегенең рәсми сайтында урнаштыруны тәэмин итәргә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитетның шәһәр хуҗалыгы һәм халык яшәешен тәэмин итү идарәсе башлыгы Р.Ф. Вилдановка йөкләргә.

Башкарма комитет
Җитәкчесе

УПРАВЛЕНИЕ ДЕЛОПРОИЗВОДСТВОМ
ЭШ КӘГАЗЬЛӘРЕН АЛЫП БАРУ ИДАРӘСЕ

Ф.Ш. Салахов

Башкарма комитетның
2026 елның 19 февралендәге
1623 номерлы карарына
кушымта

«Шәһәр хуҗалыгы дирекциясе» МАУ
тарафыннан күрсәтелә торган хезмәтләргә чик тарифлар

| № т/б | Хезмәтләрнең һәм (яки) түләүле муниципаль хезмәтнең исеме | Үлчәү берәмлеге | Бәя сум |
|---|---|---|---|
| 1 | Мунчаларда юыну хезмәтләре | | |
| 1.1 | Мунчаларның гомуми бүлегендә юыну хезмәтләре: | | |
| | Бөек Ватан сугышында катнашучылар һәм ветераннар, фашист концлагерьларының балигъ булмаган тоткыннары, «Блокадаланган Ленинградта яшәүче» билгесе белән бүләкләнгән затлар, Социалистик хезмәт Геройлары, СССР Геройлары (документ – пенсия таныклыгы күрсәткәндә) | сәгать (1 сәгать 45 минут) | бушлай |
| | Бөек Ватан сугышы инвалидлары (документ – пенсия таныклыгы күрсәткәндә) | | |
| | диализда торучы, авыру буенча инвалидлар (документ күрсәткәндә) | | |
| | хәрби хәрәкәтләр ветераннары һәм анда катнашучылар | | |
| | 7 яшькә кадәрге балалар (документ – туу турында таныклык күрсәткәндә) | | |
| | 1941 елның 22 июненнән 1945 елның 9 маена кадәрге чорда кимендә алты ай тылда эшләгән (СССРның вакытлыча оккупацияләнгән территорияләрендә эшләү чорын кертмичә) яисә Бөек Ватан сугышы чорында фидакарь хезмәт өчен СССР орденнары яки медальләре белән бүләкләнгән затлар (документ күрсәткәндә) | | 170 |
| | һәлак булган (вафат булган) Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол калган хатыннары (документ күрсәткәндә) | | |
| | барлык категория пенсионерлар | | 300 |
| | гражданнарның башка категорияләре | | 400 |
| 1.2 | Мунча номерында юыну хезмәтләре: | сәгать (60 минут) | 1133,22 |
| 1.3 | Хаммамда (төрек мунчасында) юыну хезмәтләре: | | |
| | 7 яшькә кадәрге балалар | сәгать (2 сәгать 45 минут) | бушлай |
| | 7 яшьтән 11 яшькә кадәрге балалар | сәгать (2 сәгать 45 минут) | 400 |
| | гражданнарның башка категорияләре | сәгать (2 сәгать 45 минут) | 952,81 |

| | | | |
|---|---|---|---|
| 2 | Бассейннан файдалану хезмәтләре: | | |
| | гражданннарның барлык категорияләре өчен | сәгать (45 минут) | 225 |
| | барлык категория пенсионерлар | | 170 |
| 3 | Дератизацияләү эшләре: | | |
| 3.1 | Биналарда дератизацияләү | кв.м. | 5,93 |
| 3.2 | 100 кв.м. кадәрге биналарда дератизацияләү | хезмәт | 851,42 |
| 3.3 | 100 кв.м. кадәрге биналарда бөҗәкләргә мониторинг | хезмәт | 550,90 |
| 3.4 | 101 кв.м. артык биналарда бөҗәкләргә мониторинг | кв.м. | 1,92 |
| 3.5 | Территорияләрне дератизацияләү | кв.м. | 1,61 |
| 3.6 | Шәһәрдә дезинсекцияләү | кв.м. | 25,04 |
| 3.7 | Авыл җирлегендә дезинсекцияләү | кв.м. | 27,23 |
| 3.8 | Подвалларда борчалардан, кандалалардан һ.б. дезинсекцияләү | кв.м. | 43,81 |
| 3.9 | Шәһәрдә (аерым фатирларны) дезинсекцияләү | хезмәт | 7958,06 |
| 3.10 | Талпаннарга каршы эшкәртү | кв.м. | 3,49 |
| 3.11 | Шәһәрдә чебеннәргә каршы көрәшү | кв.м. | 10,89 |
| 3.12 | Авыл җирлегендә чебеннәргә каршы көрәшү | кв.м. | 15,14 |
| 3.13 | Шәһәрдә профилактик дезинфекцияләү | кв.м. | 20,03 |
| 3.14 | Авыл җирлегендә профилактик дезинфекцияләү | кв.м. | 25,50 |
| 3.15 | Мәеттән соң фатирда профилактик дезинфекцияләү | хезмәт | 6890,93 |
| 3.16 | 10 кг кадәр керне камерада дезинфекцияләү | хезмәт | 664,12 |
| 3.17 | Автотранспортны профилактик дезинфекцияләү | хезмәт | 767,29 |
| 3.18 | Канализациягә тоташмаган бәдрәфләрне профилактик дезинфекцияләү | хезмәт | 617,35 |
| 4 | Башка хезмәтләр: | | |
| 4.1 | Бер хайванны индивидуаль тәртиптә кремацияләү (инсинераторда юк итү) | бер хайван | 8385,55 |
| 4.2 | Бер хайванны гомуми тәртиптә кремацияләү (инсинераторда юк итү) | бер хайван | 4751,25 |
| 4.3 | Хайванны шәһәр эчендә утильләштерү (Беккари чокырына илтү һәм утильләштерү) | бер хайван | 2832,29 |
| 4.4 | Хайванны шәһәрдән читтә утильләштерү (Беккари чокырына илтү һәм утильләштерү) | бер хайван | 4408,24 |
| 4.5 | Шәһәр эчендә бер хайванны йоклату һәм утильләштерү (йоклату, Беккари чокырына илтү, утильләштерү) | бер хайван | 4197,91 |
| 4.6 | Шәһәрдән читтә бер хайванны йоклату һәм утильләштерү (йоклату, Беккари чокырына илтү, утильләштерү) | бер хайван | 6409,77 |
| 4.7 | Ял көне шәһәр эчендә бер хайванны йоклату һәм утильләштерү (йоклату, Беккари чокырына илтү, утильләштерү) | бер хайван | 5767,41 |

| | | | |
|---|---|---|---|
| 4.8 | Ял көне шәһәрдән читтә бер хайванны йоклату һәм утильләштерү (йоклату, Беккари чокырына илтү, утильләштерү) | бер хайван | 8494,92 |
| 4.9 | Шәһәр эчендә сыек көнкүреш калдыкларын (минимум) чыгару | 1 м$^3$ | 668,49 |
| 4.10 | Шәһәрдән читтә сыек көнкүреш калдыкларын (максимум) чыгару | 1 м$^3$ | 1284,41 |
| 4.11 | Камаз йөк автомобилендә транспорт хезмәтләре | 1 сәгать | 3786,08 |
| 4.12 | Газель автомобилендә транспорт хезмәтләре | 1 сәгать | 2799,10 |
| 4.13 | Туфракны бар җайланмасы белән кисү | 1 кабер | 3713,50 |
| 4.14 | Биологик, медицина, азык-төлек калдыкларын утильләштерү | 1 кг | 239,70 |
| 4.15 | 100 кг кадәр биологик, медицина, азык-төлек калдыкларын ташу | 1 рейс | 4902,62 |
| 4.16 | 100 кг кадәр биологик, медицина, азык-төлек калдыкларын кабул итү, юк итү | 1 берәмлек | 4579,03 |
| 4.17 | 1000 кг артык биологик калдыкларны ташу, юк итү | 1 кг | 41,59 |
| 4.18 | Шәһәр эчендә хайванны тоту | бер хайван | 3852,35 |
| 4.19 | Шәһәрдән читтә хайванны тоту | бер хайван | 5753,81 |
| 4.20 | Ял көнендә хайванны тоту | бер хайван | 5029,41 |
| 4.21 | Җәйге шартларда кабер казу | 1 кабер | 9438,55 |
| 4.22 | Кышкы шартларда кабер казу | 1 кабер | 15935,22 |

Башкарма комитет Аппараты
Җитәкчесе урынбасары,
эш кәгазьләрен алып бару идарәсе башлыгы

МУНИЦИПАЛЬНОЕ КАЗЕННОЕ УЧРЕЖДЕНИЕ «ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ ГОРОД НАБЕРЕЖНЫЕ ЧЕЛНЫ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН»
УПРАВЛЕНИЕ ДЕЛОПРОИЗВОДСТВОМ
ЭШ КӘГАЗЬЛӘРЕН АЛЫП БАРУ ИДАРӘСЕ

Н.И. Галиева